**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Аксубаевский**
**муниципальный район**
**муниципальное образование**
**«Мюдовсюое сельское поселение»**
**423063 п. Мюд, ул. Центральная д 27**
**тел. 884344 4-04-33**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай**
**муниципаль районы**
**муниципаль беремлеге**
**"Мюд авыл җирлеге"**
**423063 Мюд авылы**
**Центральная урамы, 27**
**тел. 884344 4-04-33**

# КАРАР

**№ 13** **«19» ноября 2021 ел**

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Башкарма комитетының «2018-2035 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплексны үстерү программасын раслау турында» 17.02.2018, № 3 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003, № 131-ФЗ Федераль закон нигезендә, норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Башкарма комитетының «2018-2035 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплексны үстерү программасын раслау турында» 17.02.2018, № 3 карары белән расланган 2018-2035 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплексны үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Программаның паспортында: «Халыкны социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин итүнең максатчан күрсәткечләре (индикаторлары)» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| Социаль инфраструктура объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча планлаштырылган чараларның (инвестицион проектларнын) тасвирламасы | 2019 елда МСУ бинасы төзелеше |

2) 1.4 пунктның 4 абзацында «муниципаль заказны формалаштыру» сүзләрен «муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга; «максатчан» сүзен «дәүләт, республика, муниципаль» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

ТР Аксубай муниципаль районы Мюд
авыл жирлеге башлыгы,
Совет Рәисе: Т.В. Зюзина